РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Афанасовского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Афанас авыл жирлеге
Башкарма комитеты

423551, Нижнекамский район,
с. Большое Афанасово, ул. Молодежная,1

423551, Түбән Кама районы,
Олы Афанас авылы Яшьлер урамы, 1

тел./факс (8555) 44-43-39, электронный адрес: Afanasovskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.afanasovskoe-sp.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 31.01.2019 г. № 2

Афанас авыл җирлегендә җирләү
буенча хезмәтләрнең гаранти-
яләнгән исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен
раслау турында

«Россия Федерация сендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыручаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары белән,карар бирәм:

1. 1-нче кушымта һәм 2-нче кушымта нигезендә, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә таянып, күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2019 елның 1 февраленнән Афанас авыл җирлегендә җирләү 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Афанас авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулайук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзөстемдә калдырам.

Җитәкче Н.А. Бурмистров

Афанас авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 елның 31 гыйнварендa
2 номерлы карарына
1-нче кушымта

Афанас авыл җирлегендә 2019 елның 1 февраленнән
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар рәсмиләштерү | 46,47 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм илтү | 450 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) илтү | 450 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 5 000 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Афанас авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 елның 31 гыйнварендa
2 номерлы карарына
2-нче кушымта

Афанас авыл җирлегендә 2019 елның 1 февраленнән
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар рәсмиләштерү | 46,47 |
| 2. Гәүдәне киендерү | 245 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм илтү | 450 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) илтү | 450 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4755 |
| Барлыгы | 5946,47 |